*Муниципаль тур*

**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән республика олимпиадасының муниципаль туры биремнәре**
**2025-2026 нчы уку елы**
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 50**

## I. Тест биремнәрен эшләгез.

1. Нечкә сузыклардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) карлыган
2) төнбоек
3) зәңгәрсу
4) тәмләткеч

2. Хатасыз язылган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) үнбишләп
2) алифба
3) төнлә
4) бедрә

3. *Яшел* сүзендә я хәрефе нинди аваз белдерүен билгеләгез. **(2 балл)**
1) [а] авазын
2) [йә] авазын
3) [йа] авазын
4) [ә] авазын

4. Юлдан-юлга күчерергә мөмкин булмаган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
1) апа
2) яңгыр
3) һөнәр
4) чәүкә

5. Җөмләдәге хәбәрне билгеләгез. **(2 балл)**
*Математика дәресендә бер мәсьәләне беркем дә, хәтта Лилия дә чишә алмады.*
1) дәресендә
2) чишә алмады
3) беркем дә
4) Лилия

6. Мәкальнең дәвамын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Тимерченең кулы кара, ...*
1) тире ага.
2) эше авыр.
3) икмәге ак.
4) юылмаган.

7. Синоним сүзләрне билгеләгез. **(2 балл)**
1) төз, туры
2) эшләү, ашау
3) сөйләшү, йоклау
4) яшь, карт

8. Эчтәлегенә карап, җөмләнең ахырын дөрес билгеләгез. **(2 балл)**
*Көзнең ачы җиле ...*
1) яфракларны куалады.
2) җир өстен ак карга күмде.
3) йөгереп килде.
4) бакчаны ак чәчәкләргә күмде.

9. *Әнием* сүзе юнәлеш килешендә кулланылган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
1) әниемә әйтү
2) әниемне көтү
3) әниемнең күлмәге
4) әниемнән ишетү

## II. Теоретик бирем.

Шигырьне укыгыз. Берлек сандагы 1 һәм 2 нче зат алмашлыкларын тиешле килештә куеп, сүзләр белән языгыз. Зат алмашлыклары турында белгәннәрегезне языгыз. (**10 балл**)

**(2 зат алмашлыгы) _________** җыр бар,

**(1 зат алмашлыгы) _________** җыр бар –

Матур җырлар бик күп җирдә.

Синең җырың миңа кучсен,

**(1 зат алмашлыгы) _________** җырым **(2 зат алмашлыгы) ______**күчсен –

Җырлыйк әле бергә-бергә (*Ф. Яруллин*)

_______________________________________________

_______________________________________________

### III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

Фразеологик әйтелмә һәм аның мәгънәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) хәрәкәткә килү | 1) шәп белү |
| Ә) ут борчасы | 2) хәрәкәтчән |
| Б) су кебек эчү | 3) югалту |
| В) колак кагу | 4) ягымлы |
| Г) тәмле телле | 5) кузгалу |

**Җавап :** ________________________

### IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(4 балл)**

М...нә ике көн инде
Үзем җыештырам өйне.
Буямагыз, белегез,
Бик сакланып йөр...гез.

Җил чыкса, тузан керер,
Ф...рточканы ачмагыз.
Үзем җы....штырдым өйне,
Чисталыкны саклагыз!
(Заһирә Гомәрова)

2. Шигырьнең икенче куплетыннан басым соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**

3. *Җил* сүзенә 4 тамырдаш сүз уйлап языгыз. **(4 балл)**

4. “Чисталыкны саклыйк!” темасына 6-7 җөмләдән торган инша языгыз. (**7 балл**)